ЛЕНИНОГОРСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
ЛЕНИНОГОРСК РАЙОН
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2018 елның 29 марты №18

**Лениногорск муниципаль районы Советының «Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 19 декабрендәге 98 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

"Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына, "Лениногорск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге уставына, "Лениногорск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Советына үзгәрешләр кертү хакында" 2016 елның 29 сентябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы» Лениногорск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Советы карар кабул итте:

1. «Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» Лениногорск муниципаль районы Советының 2013 елның 19 декабрендәге 98 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 статьяга түбәндәге эчтәлекле 2.7 пункт өстәргә:

"2.7. 2019 елның 1 гыйнварына кадәр муниципаль хезмәт Вазыйфаларының өлкән һәм (яисә) кече төркемнәре Вазыйфаларын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре (урта гомуми белем булган очракта) муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфаи бурычларына "Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында" 2015 елның 25 апрелендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә катнашу кирә дигән шарт белән куелмый."

2.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лениногорск муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Н.Г. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Лениногорск муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Г.Хөсәенов